Кабул ителде
Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре
11 нче номерлы “Бал корты” балалар
бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль
бюджет учреждениесе
педагогик советында
Беркетмә №1 от «31» 08 2018 г.

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре
11 нче номерлы “Бал корты” балалар
бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль
бюджет учреждениесе мөдире
_________Т.А.Абакшина
Гамәлгә кертелде
Боерык №129 от «31» 08 2018

**Икенче нәниләр төркеменең**
**2018-2019 нче уку елына**
**эш программасы**

Эшләде: I квалификацион категорияле тәрбияче
Кабирова Миләүшә Таһирҗан кызы

Нурлат шәһәре
2018-2019 нчы уку елы

2018-2019 нчы уку елы

Эчтәлек

1Аңлатма язуы.

2.Балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре

3.Балалар бакчасында икенче нәниләр төркеме балаларының режим моментларын оештыру

4.Көндәлек режим

5.Белем бирү эшчәнлеге челтәре

6.Комплекслы- тематик план

7.Психолого-педагогик эшчәнлекнең әчтәлеге :

Нәфис-нәфасәти үсеш

-Рәсем ясау буенча перспектив план

-Әвәләү буенча перспектив план

Танып белү

-Табигать белән таныштыру / иҗтимагый тәрбия бирү буенча перспектив план

Сөйләм үсеше

-Матур әдәбият укубуенча перспектив план

-Сөйләм үстерү буенча перспектив план

Физик үсеш :физик тәрбия бирү буенча перспектив план

Иҗтимагый – шәхси үсеш

8.Методик әдәбият

9. Ата-аналар белән эш планы

10.Эш программасының проекты

11. Предметлы тирәлек мохитны үстерү

## Аңлатма язуы

Әлеге программа “Туган телдә сөйләшәбез” укыту-методик комплектына һәм Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 11 нче номерлы “Бал корты” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесенең белем һәм тәрбия бирү программасына нигезләнеп төзелде.

Программа белем бирү процессын эшкә ашыруны өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеген, балаларның мөстәкыль эшчәнлеген үз эченә алган ике төп оештыручы модель ярдәмендә тәэмин итә; 2 яшьтән 3 яшькә кадәр булган балаларга белем биргәндә яшь үзенчәлекләренә тәңгәл килерлек укыту моделен күздә тота.

**Программаның максаты**.Программа балада һәрьяклы (физик, шәхси, танып белү, рухи, эстетик) үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура, туган якны, туган телне (татар һәм рус) өйрәнү аша аның баетылуын күздә тота.

**Программа буенча түбәндәге бурычлар куела:**

-балаларның сәламәтлеген ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше алып баруга этәрү, физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту;

-балаларда әйләнә –тирә дөньяга карата гуманлы караш үстерү, туган илне, туган телне яратырга этәрү, сөйләм культурасы һәм кешеләргә мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү;

-балаларда иҗади сәнгатькә, матур әдәбиятка карата кызыксыну уяту.

Бу бурычларны тормышка ашыру төрле төр эшчәнлек барышында тормышка ашырыла:

- балаларның төрле төр эшчәнлек барышында тормышка ашырыла.(уен, аралашу,хезмәт, танып белү, матур әдәбият уку, иҗади сәнгать),
- төрле режим моментларында белем эшчәнлеге процессында,
- балаларның мөстәкыль эшчәнлек вакытында,

Балаларга белем бирү эшчәнлеге атнага, программа һәм САНПиН буенча, ун шөгыльдән артмаска һәм үткәрү вакыты 8-10 минут булырга тиеш.

Программа буенча түбәндәге максатлар:

-һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;

- балаларның аралашучан, игелекле, кызыксынучан, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлеген күтәрү максатыннан аларны интеграцияләү.

### 2-3 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре

Өченче яшьтә балалар мөстәкыйльрәк була башлыйлар. Предметлы эшчәнлек, бала белән өлкәннәрнең ситуатив- эшлекле аралашулары үсә бара, кабул итүчәнлекләр, сөйләм, үз-үзләрен ирекле тотуның башлангыч формалары, уеннар, күрсәтмәле-тәэсирле фикер йөртүләре камилләшү.

Предметлы эшчәнлек үсеше төрле предметлар белән куьтуралы эш итү ысулларын үзләштерүгә бәйле. Мөнәсәбәттәш һәм кораллы эш гамәлләр үсә.

Охшарга тырышу обүекты сыйфатында һәм шулай ук балаларның үз активлыгын да үстерүче үрнәк итеп олылар тәкүдим иткән модель нигезендә, кораллы эш-гамәлләр табигый активлыкны, белем һәм күнекмәләр ярдәмендә барлыкка килүче активлыкка үзгәртеп, баланың ирекле тәртибен үстерәләр.

Олылар белән уртак предмет эшчәнлеге барышында сөйләмне аңлау үсә. Сүз ситуациядән аерыла һәм мөстәкыйль мәгънә ала бара. Балалар үзләрен әйләндереп алган предмет исемнәрен үзләштерүләрен дәвам итәләр, олыларның гади сүз белән белдергән үтенечләрен үтәргә өйрәнәләр.

Бала аңлый торган сүзләр саны шактый арта. Бала олыларның күрсәтмәләрен генә түгел, ә аларның хикәяләүләрен дә аңлый башлый. Моңа бәйле рәвештә олыларның мөрәҗәгате нигезендә балаларның  тәрпитләрен көйләү камилләшә.
Балаларның актив сөйләме интенсив үсә. 3 яшькә алар төп грамматик структураларны үзләштерәләр, гади җөмләләр төзергә тырышалар, өлкәннәр белән сөйләшкәндә барлык сүз төркемнәрен дә диярлек кулланалар. Актив сүзлек якынча 100-1500 сүзгә җитә. 3 яшь туларак сөйләм баланың яшьтәшләре белән аралашу чарасына әйләнә. Бу яшьтә балаларда уен, рәсем ясау, конструкөияләү кебек яңа эшчәнлек төрләре формалаша.
Уен процессуаль характер ала, анда иң мөһиме эш хәрәкәтләр. Балалар чын барлыкка якынлаштырылган уен предметлары белән уныйлар. Өченче яшьнең урталарында бер предметны икенчесе белән алыштырып уйнау күнекмәләре барлыкка килә.
Балалар бакчасында беренче кечкенәләр төркеме балаларының режим моментларын оештыру
Көндәлек режим ул- балаларның эшчәнлек төрләре һәм ялының  рациональ дәвамлылыгы, дөрес чиратлашуы. Режим моментлары түбәндәгеләрне истә тотып төзелде:

- балаларның  төркемдә булу вакытлары;
- гамәлдәге санитария нормалары һәм кагыйдәләре(Сан Пин);
- мәктәпкәчә  белем бирү өлкәсендә федераль  дәүләт таләпләре;
- белем бирү процессын тормышка ашыруның  үзенчәлекле шартлары (климатик, демографик, милли-мәдәни һ.б.);
- ел фасыллары.

Программаны үзләштерү, тормышка ашыру буенча өлкәннәр  һәм балалар эшчәнлеге көндәлек режимда  ике төп модельдә оештырыла: өлкәннәр һәм балаларның  уртак эшчәнлеге, балаларның мөстәкыль эшчәнлеге
. Икенче кечкенәләр төркеме балаларының исемлеге

| |
|---|
| Бадрутдинов Роберт Альбертович |
| Калыгин Мирон  Николаевич |
| Хисматуллина Ясмина Рамисовна |
| Логинов  Матвей Александрович |
| Мухтарова Александра Вадимовна |
| Мулюкова Лиана  Разилевна |
| Нуруллина  Эмилия Артуровна |
| Мифтахова Ева Рамилевна |
| Ратуева Арина Димитриевна |
| Сидорова Дарья Антоновна |
| Осипова Лиза Дмитриевна |
| Семенова Анна Антоновна |
| Самигулова Ралина Ильдаровна |
| Тойменев Захар Алексеевич |
| Хуснутдинова Амалия Рустемовна |
| Абдулганеева Динара Фанилевна |
| Хайруллина Амиля Рамилевна |
| Шакирова  Ильнара Ильхамовна |

Тальков Тимур Игоревич

Белем бирү эшчәнлеге челтәре

| Икенче нәниләр төркеменең белем бирү эшчәнлегенең җәдвәле | | |
|---|---|---|
| **Дүшәмбе** | 1. Сөйләм үсеше<br>2. Сәнгать үсеше (Музыка)<br>Реж.м Конструкцияләү | 8.40 – 8.50<br>15.30-15.40 |
| **Сишәмбе** | 1. Физик үсеш (саф һава)<br>2. Сәнгать үсеше **(**Рәсем ясау)<br>Реж.м Танып белү үсеше (МЭКФ) | 8.40-8.50<br>15.30-15.40 |
| **Чәршәмбе** | 1. Сәнгать үсеше (әвәләү)<br>2. Физик үсеш | 8.40 – 8.50<br>15.30-15.40 |
| **Пәнҗешәмбе** | 1. Танып белү үсеше (бала һәм әйл.-тирә)<br>2.Сәнгать үсеше(Музыка) | 8.40-8.50<br>15.30-15.40 |
| **Җомга** | 1. Сөйләм үсеше<br>2. Физик үсеш | 8.40-8.50<br>15.30-15.40 |

**Көндәлек режим(елның салкын вакыты)**

| | |
|---|---|
| Кабул итү, ирекле уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек | 6.30- 7.50 |
| Иртәнге гимнастика | 7.50- 7.55 |
| Иртәнге ашка әзрлек, иртәнге аш | 7.55- 8.20 |
| Уеннар ,мөстәкыль эшчәнлек | 8.20- 8.30 |
| Оештырылган белем бирү эшчәнлегенә әзерлек, белем бирү эшчәнлеге, мөстәкыль эшчәнлек | 8.40- 9.00 |
| Икенче иртәнге аш | 9.00- 9.10 |
| Саф һавада йөрүгә әзерлек,саф һавада йөрү | 9.10- 11.00 |
| Кайту,мөстәкыйль эшчәнлек | 11.00-11.15 |
| Төшке ашка әзерләнү, төшке аш | 11.15- 12.00 |
| Йокыга әзерләнү, көндезге йокы | 12.00- 15.00 |
| Йокыдан тору, сулыш гимнастикасы,чыныгу күнегәләре | 15.00-15.15 |
| Төштән соңгы аш | 15.15- 15.30 |
| Оештырылган белем бирү эшчәнлеге | 15.30- 15.40 |
| Оештырылган балалар эшчәнлеге, мөстәкыйль эшчәнлек, уеннар | 15.40-15.55 |
| Кичке ашка әзерлек, кичке аш | 15.55- 16.25 |
| Саф һавада йөрүгә әзерлек,саф һавада йөрү | 16.25-18.00 |
| Саф һавадан кайту, мөстәкыйль эшчәнлек,өйгә кайту | 18.00 -18.30 |

**Көндәлек режим (елның җылы вакыты)**

| | |
|---|---|
| Кабул итү, ирекле уеннар, мөстәк.эшчәнлек | 6.30- 7.50 |
| Иртәнге гимнастика | 7.50- 8.00 |
| Иртәнге ашка әзрлек, иртәнге аш | 8.00- 8.30 |
| Уеннар ,мөстәкыль эшчәнлек | 8.30- 9.00 |
| Икенче иртәнге аш | 9.00- 9.10 |
| Саф һавада йөрүгә әзерлек,саф һавада йөрү | 9.10- 11.10 |
| Кайту,мөстәкыйль эшчәнлек | 11.10-11.20 |
| Төшке ашка әзерләнү, төшке аш | 11.20- 12.00 |
| Йокыга әзерләнү, көндезге йокы | 12.00- 15.00 |
| Йокыдан тору, сулыш гимнастикасы,чыныгу күнегәләре | 15.00-15.15 |
| Төштән соңгы аш | 15.15- 15.25 |
| Оештырылган балалар эшчәнлеге,<br>мөстәкыйль эшчәнлек, уеннар | 15.25- 15.55 |
| Кичке ашка әзерлек, кичке аш | 15.55- 16.25 |
| Саф һавада йөрүгә әзерлек,саф һавада йөрү | 16.25-18.00 |
| Саф һавадан кайту, мөстәкыйль эшчәнлек,өйгә кайту | 18.00 -18.30 |

Комплекслы- тематик план
Икенче нәниләр төркеме

| Темалар | Үткәрү вакыты | Белем бирү өлкәләр | Эшчәнлекнең максатлары | Эшчәнлек төрләре һәм эчтәлеге | Йомгаклау чаралары |
|---|---|---|---|---|---|
| Балалар бакчасы | Августның 4нче атнасы, сентябрь 1-2 нче атнасы<br>24 августан-13 сентябрь | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасэти үсеш | Балаларны балалар бакчасы белән (группа, шәхси шкафлары, йокы бүлмәсе, уенчыклар) таныштыру., Тәрбиячеләр, кече тәрбияче белән таныштыру. Балаларда бакчага, тәрбиячеләргә, балаларга карата уңай эмоцияләр булдыру. | 1. Балалар, эти – әниләре белән танышу.<br>2. Әти –әниләрне балалар бакчасының эшләү режимы белән таныштыру.<br>3. Балаларны балалар бакчасы белән (группа, шәхси шкафлары, йокы бүлмәсе, уенчыклар) таныштыру.<br>4. “Баланы балалар бакчасына әзерләү” эти-әниләр белән әңгәмә.” | |
| Юл йөрү кагыйдә- | Сентябрь<br>3-4 атнасы<br>14 сентябрь-27сентябрь | Танып белү, Физик үсеш | Балаларның юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен киңәйтү. Балала рның юл йөрү | 1. Юл йөрү билгеләре белән таныштыру.<br>2 Юл йөрү кагыйдәләре | “Зур шәһәрдә нәни юл |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| ләре кирәк безгә һәр көнне | | Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | кагыйдәләре турында фикерләү сәләтен, игътибарларын үс терү.Балаларга юл йөрү билгеләрен һәм яңа терминнар өйрәтү.Транспорт төрләре белән таныштыру. | буенча әкиятләр уйлап чыгару<br>3. Юл йөрү кагыйдәләре буенча рәсем ясау (әти-әниләр белән берлектә). | йөрүчесе" Әти-әниләр белән берлектә рәсем конкурсы. |
| Табигатьтә көз. | Октябрьнең 1-2 атнасы 1 Октябрь -18 Октябрь | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | Балаларның ел фасыллары турында белемнәрен киңәйтү: көзнең харак терлы үзенчәлекләре, табигатьтәге үзгәрешләр, кыр һәм йорт хайваннарының тормышы, кошлар тормышы, кешеләрнең эшчәнлеге. | 1."Көз килде" әңгәмә<br>2. "Алтын көз" темасына рәсемнәр ясау(әти-әниләр белән берлектә).<br>3. "Яшелчәләр өлгерде" әвәләү. Җиләк-җимеш кибете | Көзге уңыш" бәйрәме (әти-әниләр белән берлектә) Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Мин — дөньяның бер кешесе | Октябрьнең 3-4 атнасы Ноябрьнең 1 нче атнасы 19 Октябрь 8 Ноябрь - - | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | Балада, кеше буларак, үзе турында күзаллау булдыру; кеше гәүдәсенең төп өлешләре һәм аларның ни өчен кирәклеге белән таныштыру. Үз исе-мен, гаилә әгъзаларының исемнәрен белүләренә ирешү. Нәрсә нең яхшы, нәрсәнең начар булуы, сәламәт тор-мыш образы турында башлангыч күз-ал лау булдыру | 1. "Минем гайләм" әңгәмә<br>2. "Әби-бабай, дәү әти- дәү әни" әңгәмә<br>3. "Мин бәхетле әби бабам белән" фотоколлаж. | Мин бәхетле әби бабам белән" (әти-әниләр белән берлектә) фотоколлаж. |
| Минем әйләнә-тирәм | Ноябрьнең 2 -4 нче атнасы 9 Ноябрь-29 Ноябрь | Танып белү, Физик үсеш Социаль- | Балаларны туган шәһәрләре (авыл-лары): аның исеме, объектлары (урам, йорт, кибет, шифаханә) һәм | 1." Без Татарстанда яшибез "әңгәмә.<br>2. "Казан буйлап сәяхәт" рәсемнәр карау, әңгәмә.<br>3.. Ата-аналарга | "Әниләр иң кадерле кешеләр" фотоко |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | транспорт, һөнәрләр (табиб, сатучы, полиция хез-мәткәре) белән таныш тыру. | музейларга ял көннәрендә экскурсия ясарга тәкъдим итү.<br>4. Төрле һөнәрләр белән таныштыру рәсемнәр карау. | ллаж. |
| Яңа ел | Декабрьнең 1-4 нче атнасы 1 Декабрь 27 Декабрь | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | Яңа елга һәм Яңа ел бәйрәменә кагы-лышлы эш чәнлекнең барлык төрен (уен, коммуникатив эш чәнлек, хезмәт, танып белү, тикшеренү, продуктив, музыкаль эш чәнлекләр, укулар) оештыру. | 1. “Чыршы янында бәйрәм” рәсем ясау.<br>2. “Яңа ел “турында шигырьләр.<br>3. “Яңа ел” турында җырлар өйрәтү.<br>4. ” Яңа ел” уенчыклары күргәзмәсе (әти-әниләр белән берлектә).<br>5 . Участокта әти-әниләр белән тау ясау.<br>6. “Иң гузәл группа” конкурсында катнашу. | Яңа ел бәйрәме |
| Кыш | Гыйнварның 2-4 атнасы 11 Гыйнвар - 31Гыйнвар | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | Кыш турында күзаллау формалашты ру (та бигатьтә сезон үзгәрешләре, ке шеләрнең кие ме, балалар бакчасы мәй даны). Балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турында бе лемнәрен ки ңәйтү. Кыш көне урман җәнлек ләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзен чәлекләре белән таныштыру. | 1. “Кар патшасы” әвәләү<br>2. Кышкы табигатькә экскурсия, җимлекләр элү.<br>3. “Кар патшабикәсе”әкиятен уку, рәсемнәр карау.<br>4. “ Серле кар бөртекләре” (әти-әниләр белән берлектә эш). | “Туганн ягымда кыш” күргәзмә |
| Әтиләр һәм әниләр, бабайлар | 1. Февраль- 6 Март — | Танып белү, Физик үсеш Социаль- | Гаиләгә, әнигә, әбигә, әтигә мәхәббәт темасына кагылышлы эшчәнлекнең барлык төр ләрен оеш тыру | 1 Ватанны саклаучылар көненә багышланган рәсемнәр карау.<br>2.. Әтиләргә бүләк.<br>3. 8март – халыкара хатын кызлар көне | “Мәрхәмәтле газиз әнием” әниләр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| һәм әбиләр | | шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | (уен, коммуни-катив, хез мәт, танып белү, тикше ре нү, продуктив, музыкаль эшчәнлекләр, укулар). | турында әңгәмә<br>4. Әниләргә бүләк. | бәйрәме |
| Халык иҗаты | 7 Март – 27 март | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | Балаларны халык иҗаты белән таныштыру. Халык авыз иҗаты (җырлар, бармак уенна ры һ.б.) белән таныш тыру. Балалар эшчәнлеге нең барлык төрләрен оеш тырганда, фольклор элементларын куллану. | 1. Халык иҗат иткән уенчыклар, уеннар белән танышу<br>2. Халык әкиятләре белән танышу.<br>3. Бармак уеннары. | Уеннар. Халык иҗат иткән уенчыклар күргәзмәсе. |
| Табигатьтә яз. | 28 Март – 17 Апрель | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис-нәфасәти үсеш | Яз турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә, ба лалар бакчасы мәй данында сезон үзгә решләре). Йорт хайваннары һәм йорт кошлары турында белемнәрен киңәй тү. Яз көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. | 1. Яз турында әңгәмә<br>2. “Туган ягыма яз килде” рәсемнәре карау<br>3. Язга багышланган җырлар. | Яз бәйрәме |
| Габдулла Тукайның әкият дөньясы | Апрельнең 3-4 атнасы 18Апрель -30 Апрель | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйлә | Балаларны Г. Тукайның иҗаты белән таныштырырга. Әдәби әсәрләрне тыңлый белүләренә ирешү. Әкиятләргә мәххәбәт тәрбияләү. | 1. Габдулла Тукай белән таныштыру.<br>2. Г. Тукайның “Су анасы” әкиятен уку<br>3. Г. Тукайның “Шүрәле” әкиятен уку | Тукай әсәрләренә сәяхәт Рәсем конкурсы кул эшләмәләре |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | м үсеше Нәфис - нәфас эти үсеш | | | күргәзм зсе. Әти әниләр белән |
| Җәй | Майның 1-4 атнасы 2 Май-31 Май | Танып белү, Физик үсеш Социаль-шәхси үсеш Сөйләм үсеше Нәфис - нәфас эти үсеш | Җәй турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә, балалар бакчасы мәйданында сезон үз-гәрешләре). Йорт хайваннары һәм кош-лары, яшелчәләр, җиләк-җи мешләр турында белемнәрен киңәйтү. Җәен урман җәнлекләре һәм кош ларының үз-үзләрен тоту үзен чәлекләре белән таныштыру. Җылы якларда яшәүче кайбер хайваннар белән таныштыру. | 1. Кыргый хайваннарның рәсемен карау<br>2. Йорт хайваннарның рәсемен карау<br>3. Үсемлекләр рәсемен карау | Әти Әниләр берлектә бакча мәйдан чыгын бизәү. |

**Нәфис-нәфасәти үсеш**

**Рәсем ясау**

Балаларга рәсемнәрдә әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгын (миләш тәлгәшләре, җиргә коелучы төрле төстәге яф-раклар һ. б.ны) сурәтләп бирергә тәкъдим итү. Балаларны сәнгать әсәрләрен кабул итәргә әзерләү. Сәнгать әсәрләренең матурлыгына уңай эмоциональ караш тәрбияләү. Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: милли орнамент элементларын (лалә, күкчәчәк, кыңгырау чәчәк, яфраклар һ. б.ны) буяу ысулларын күрсәтү. Сурәтләнә торган предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү.
Татар орнаментына хас булган төс исемнәрен (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара) белүләрен ныгыту. Бер, ике яки берничә төсне кулланып, сурәтләр тасвирларга өйрәтү.
Балаларны төрле юнәлештә туры сызыклар (кыска, озын, вертикаль, горизонталь, авыш) сызарга өйрәтү. Төрле форма-дагы (түгәрәк, турыпочмаклы) предметлар сурәтләүгә өйрәтү.

Әвәләү

Әвәләү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Балчык, пластилин, тозлы камырның үзлекләре һәм аларны әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларын ныгыту. Балчык, пластилин кисәкләрен туры һәм әйләнүле хәрәкәт белән әвәләү; ике кулның уч төпләре белән басып, шарны яс-сыландыру. Уйнау өчен гади генә формалар – коймак, кабарт-ма, мич күмәчләре әвәләргә дәртләндерү.Балчык, камыр белән пөхтә эш итү күнекмәләрен ныгыту; әвәләп ясалган әйберләрне һәм кисәкләрне әвәләү тактасына кую. Әвәләнгән фигуралардан күмәк композиция төзергә тәкъдим итү (поднostагы пәрәмәчләр, чәй сервизы һ. б.). Күмәк эшчәнлекнең нәтиҗәсен күреп, шатлану хисләре тудыру.
«Музыка» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели. Татар халык музыкасы һәм татар композиторларының музыкасына, музыка астында башкарылган хәрәкәт импро-визацияләренә (үзлектән яки тәрбияче ярдәмендә) уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

Курай, тальян гармун һ. б. музыкаль инструментларны яңгырау тавышыннан таный белү күнекмәләре формалаштыру. Татар биюләренә хас булган гади хәрәкәтләр («аяк очла-рында атлап йөрү», «бер аяк белән тыпырдау», «борма» (гади вариант), «култыклашып әйләнү» һ. б.) белән таныштыру. Биисе килү теләге уяту. Музыканы балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә фай-далану. Кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә булыш-лык итәрлек музыка астында матур әдәбият һәм сынлы сәнгать әсәрләре кулланып, катнаш музыкаль шөгыльләр үткәрү.
Тәкъдим ителгән музыкаль әсәрләр
Рәсем ясау.
Балаларга рәсемнәрдә әйләнә-тирә табигатҗнең матурлыгын сурәтләп бирергә тәгъдим итү.
Балаларны сынлы сәнгать әсәрләрен кабул итәргә әзерләү. Татар декоратив-гамәли сәнгатьнең иң гади бизәк элементлары һәм аларн белән бизәлгән көнкүреш предметлары белән таныштыру.
Татар орнаментына хас булган төс исемнәрен (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара) белүләрен ныгыту. Балаларның инициатива, мөстәкыйльлек күрсәтүләрен, башланган эшне ахырына кадәр җиткерә белүләрен хуплау.
Балаларны төрле юнәлештә туры сызыклар (кыска, озын, вертикаль, горизанталь, авыш) сызарга өйрәтү. Төрле формадагы предметлар сызарга өйрәтү.
Рәсем ясау буенча перспектив план

| ай | 1 нче атна | 2 нче атна | 3 нче атна | 4 нче атна |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | | | Тема:Шарларга җеп бәйлибез | Тема:Яңгыр ява. |
| | | | Максат: карандашны дөрес тотарга өйрәтүне дәвам итү; туры сызыкларны өстән аска таба ясарга өйрәтүне дәвам итү; | Максат: өстән аска таба ясарга өйрәтүне дәвам итү. Красканы кисточкага ала белергә, төрле төсләр куллаганда кисточканы башта юарга өйрәтү. |
| Октябрь | Тема: Серпантин | Тема: Төрле төстәге шарчыклар | Тема: Түгәрәкләр | Тема: Кабар син шар |
| | Максат:образлы кузаллау формалаштыру. Кисточканы дөрес тотарга, гуашька тиде реп артыгын банка кырыенда калдырырга өйрәтү. Кисточ каны кырые белән альбом би тенә тидереп ясарга өйрәтү. | Максат: рәсемдәге түгәрәк формаларны күрсәтү; рәсем ясау барышында төрле төстәге карандашлар куллана белү. Төсләр белүне ныгыту. | Максат: рәсемдәге түгәрәк формаларны күрсәтү; рәсем ясау барышында төрле төстәге карандашлар куллана белү. Төсләр белүне ныгыту. | Максат: хәрәкәтле уен образын рәсемдә чагылдыру. Түгәрәк формадан предметлар ясый белүне ныгыту. Кузаллауны ныгыту. |
| Ноябрь | Тема: Тәм том. | Тема: Чебиләргә бөртекләр. | Тема: Әкәм-төкәм эзе. | Тема: Йолдызлы күк йөзе. |
| | Максат: муляңларга карап түгәрәк формасындагы тәм томнар ясарга өйрәтү. | Максат: Түгәрәк формалы предметлар ясарга өйрәтүне дәвам итү. Кисточка белән | Максат: кисточка белән эзлексез сызыклар ясарга өйрәтү; узең ясаган рәсемгә куану хисен | Максат: кара төстәге картонга сары төстәге гуаш белән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Рәсем ясауга кызыксыну уяту. | куллана белүне ныгыту. | тудыру. | бармаклар белән йолдызлар төшерү. Чиста пөхтә эшләргә өйрәтү. |
| Декабрь | Тема:Карлар ява | Тема: Чыршы бизибез. | Тема: Куяннарга булыш | Тема: Өйгә тәрәзә |
| | Максат: зәңгәр төстәге картонга ак гуаш белән бармаклар белән йолдызлар төшерү. Чиста пөхтә эшләргә өйрәтү. | Максат: Картоннан чыршы формасында киселгән битне бизәү.. Краскалар белән буйый белергә өйрәтүне дәвам итү | Максат: балалар белән ярмада бармаклар белән ясау, куян аягы эзен төшерү. | Максат: Теремкәй әкияте буенча алдан әзерләгән өйгә тәрәзә ясау. |
| Гыйнвар | | Тема: Яңа ел чыршысы | Тема: Зил зилә. | Тема: Тәлинкә. |
| | Кышкы каникуллар. | Максат:бизәлгән чыршы формасын рәсемдә чагылдыра белү. Ал , зәңгәрсу төсләр белән таныштыру. | Максат: кышкы җилләр бураннар турында сөйләү. Ул күренешне ничек кәгазгә төшерүне аңлату. | Максат: кисточка белән түгәрәк формасы ясау. Краскалар белән буйый белергә өйрәтүне дәвам итү |
| Февраль | Тема: Тычкан оясы | Тема: Күкәй | Тема: Әтәчемә борчак | Тема: Сигезаяк |
| | Максат: алдан әзерләнгән “тычкан оясы” түгәрәкне кырыйларыннан чыкмыйча ак урыннар калдырмый буярга өйрәтү. | Максат:.Ряба исемле тавык әкияте. Бәрәңгедән эз калдыруны ныгыту. Төрле төсләр куллану. | Максат: бармаклар белән ясауны дәвам итү, чиста пөхтә эшләүне тәрбияләү. | Максат: Уч белән рәсем ясау техникасы белән таныштыру. Балалрда кызыксыну уяту. |
| Март | Тема: Матур флажоклар | Тема: Әниемә чәчәк | Тема: Кояшкай | Тема:Язгы сөңгеләр |
| | Максат: турыпочмаклы предметларны вертикаль, горизонталь сызыклар аша сурәтләү. Турыпочмаклы форма белән таныштыру. | Максат: балаларга матур күренешләрне предметларны күрә белергә өйрәтү. | Максат:.бармаклар белән круг, нурлар ясау. Вак моториканы ныгыту. Теләк буенча күзләр, борын , елмаю ясау | Максат:  баларны бармаклар белән вертикалҗ сызыклар ясарга өйрәтү. Краскалар белән буйый белергә өйрәтүне дәвам итү |
| Апрель | Тема: Дулкыннар | Тема: Баскычлар | Тема: Йомгагым | Тема: Үлән арасында |
| | Максат: Кисточка белән дулкыннар ясау. Төсләрне дөрес куллану, аеруны өйрәтү. | Максат:  поролон белән буяуны ныгыту. Баскычлар ясау. | Максат: Кисточка белән йомгак ясау. Төрле төсләр куллану. Чиста пөхтә эшләргә өйрәтү. | Максат: Кисточка белән өстән аска таба кыска сызыклар – үсеп утыручы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | үлән ясау. |
| Май | Тема: Бәйрәм картинасы | Тема: Тузганак чәчәге | Тема:Ирекле рәсем | Тема: Камка |
| | Максат: Алган тәэсирләргә бәйләп, үзең ясаган рәсемнең эчтәлеген уйлап табу. | Максат: чәчәкләрнең формаларын, чәчәкле болынны рәсемдә чагылдыра белү теләген уяту. | Максат: үзләреннән рәсем ясый белүне үстерү. Тиешле буяуларны сайлый белергә өйрәтү. | Максат: Алдан өйрәнгәннәрне ныгыту, төрле зурлыктагы түгәрәкләр ясау. |

**Әвәләү**

Әвәләү эшчәнлеге белән кызыксыну уяту.Тозлы камыр, балчык, пластилинның үзлекләре һәм аларны әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларны ныгыту. Балаларның иҗади сәләт һәм инициативаларын үстерү. Әвәләү балаларда вак моториканы үстерә, тоемлау хисе сенсорик тәҗрибә булдырыла—форма, авырлык, сыгылмалык, йомшак һ б. Балалар үз эшләрен планлаштырырга, ахырына җиткерергә өйрәнәләр.

Балчык, пластилин кисәкләрен туры һәм әйләнүле хәрәкәт белән әвәләү; ике кулның уч төпләре белән басып, шарны яссыландыру. Уйнау өчен гади генә формалар -- коймак, кабартма, мич күмәчләре әвәвләргә дәртләндерү.

Балчык, тозлы камыр белән пөхтә эш итү күнекмәләрен ныгыту, әвәләп ясалган әйберләрне һәм кисәкләрне әвәләү тактасына кую.

Әвәләү буенча перспектив план

| ай | 1нче атна | 2 нче атна | 3нче атна | 4нче атна |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | | | Тема: Төсле акбурлар | Тема: Курчакка кәнфитләр. |
| | | | Максат: Пластилин кисәкләрен туры хәрәкәтләр белән әвәләү күнекмәләрен; артык кисәкләрне әвәләү тактасына куя белү. | Максат: Эшләү алымын аңлату, эшләп карау, балаларга юнәлеш бирү Һәм ярдәм итү, кәгазьгә төреп курчакларны сыйлау. |
| Октябрь | Тема: Йомры икмәк | Тема: Минем тубым | Тема: Кыяр | Тема: Алмалар. |
| | Максат: Әкият персонажларын әвәләүдә сурәтләү теләге уяту. Түгәрәк формадагы предметлар әвәләүне ныгыту. | Максат:Түгәрәк формадагы предметлар әвәләүне ныгыту.Чиста, пөхтә эшләргә өйрәтү. . | Максат: Овал формадагы предметлар әвәләүне ныгыту.Чиста, пөхтә эшләргә өйрәтү. Яшелчәләр турында мәгълүмат бирә, төсләр тануны өйрәтүне дәвам итү.. | Максат: Муляжлар карау, формасына , зурлыгына игътибар иттерү, түгәрәк шарсыман фигуралар әвәләүне искә төшерү. |
| Ноябрь | Тема: Клиндерләр. | Тема: Печенье | Тема: Көнбагыш | Тема: Нәни еланнар. |
| | Максат: Туры юнәлештә әвәләү алымын ныгыту. Иптәшләрнең эше | Максат: Пластилинны түгәрәк хәрәкәтләр белән әвәләргә; уч төпләре белән сытарга | Максат: Балаларны пластилиннан кечкенә кисәкләр алып аларны учта | Максат: Балаларны тактада пластилиннан валик тәгәрәтергә өйрәтү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән үзенекен чагыштыра белү, аерыманы күрә белү. | өйрәтү. әвәләү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. | тәгәрәтеп бармаклар белән форма кертергә өйрәтүне дәвам итү. | Чиста, пөхтә эшләргә өйрәтү. |
| Декабрь | Тема: Шалтыравыклар | Тема: Кар бабайга борын | Тема: Кабартмалар | Тема: Яңа ел уенчыгы |
| | Максат: Таякчык әвәләүне ныгыту , шарчыктан һәм таякчыктан бер педмет килеп чыгуын исбатлау, , такта янында 2-3 баладан эшләтеп карау., | Максат: Балаларны учта шар формасын тәгәрәтеп ясауны өйрәтүне дәвам итү, кишер формасын ясау, балаларда эшкә кызыксыну тәрбияләү, | Максат: Әңгәмә үткәрү “ ИПИ бик кадерле нәрсә”Курчакларны кунакка чакыру , кабартма әвәләү ысулын өйрәнү, эшне анализларга өйрәтү | Максат: Әвәләүнең төрле алымнарын кулланып чыршы уенчыгы әвләү. |
| Январь | Кышкы каникуллар | Тема: Яңа ел чыршысы | Тема: Тәмле бәлеш | Тема: Шалкан |
| | | Максат: : Балаларны учта шар формасын тәгәрәтеп ясауны өйрәтүне дәвам итү, анализларга өйрәнүне дәвам итү | Максат:Балаларны шарны учта җәергә өйрәтү, мәлешне бизәү, кәеф күтәренкелеге булдыру, эш алымнарын балалардан сорап ныгыту. | Максат: Шалкан элементларын эвләү:шар формасы, аны җәю, койрыгын сузып алу, яфраклар өстәү. (Учта тәгәрәтеп, бармаклар белән) |
| Февраль | Тема: Банан | Тема: Гөмбәләр | Тема: Самолет | Тема: Чебиемә кортлар |
| | Максат: чикләнгән контурдан чыкмый гына пластилинны тигез итеп җәюне ныгыту. Җиләк җимешләрне тәмнәре, формалары буенча аеру. | Максат:Гөмбә өлешләре: аягы: шләпәсе, утыра торган алан әвәләү. . Пластилин кисәгеннән күз кәүеме белән тигез ике өлешкә бүлә белү. | Максат: Таякчык әвәләүне ныгыту, ике төрле таякчыктан бер педмет килеп чыгуын исбатлау, , такта янында 2-3 баладан эшләтеп карау., д\уен “Самолет оча” | Максат: пластилин кисәгеН ике уч арасында түгәрәк хәрәкәтләр ясап тәгәрәтергә; берничә йлештән торган предметлар әвәләргә өйрәтү. |
| Март | Тема: Әниемә бүләк | Тема: Курчакларга кунак ашы | Тема: Боз сеңгеләре | Тема: Аумас курчак |
| | Максат: Картонга бирелгән контурда пластилиннан төрле төсләрдә ясап чәчәк ямау. Әниләргә бүләк ясау узе шатлык икәнне аңлату. | Максат: Кунакка килгән курчакның нинди ризык белән сыйланырга теләвен ачыклау, зурлыкларга игтибар итеп, әвәләргә кирәклеген төшендерү. | Максат: Боз сеңгеләре турында мәгълүмат бирү, төзелешен , формасын ачыклау, өлешләрнең зурлыгына игътибар итү. | Максат: Аумас курчакны күзәтү, төзелешен , формасын ачыклау, өлешләрнең зурлыгына игътибар итү, өлешләрне дөрес, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Пластилиннан әвәләү. | пөхтә итеп беркетү |
| Апрель | Тема: Тәлинкәдә җиләкләр | Тема: Мин тәмлеләр пешерәм | Тема: Күпер | Тема: Керпе |
| | Максат: Бер зур тәлинкә ясау (алдагы үткәннәрне искә төшерү), кечкенә кисәкләрдән җиләкләр әвәләү.(учта тәгәрәтеп бармаклар белән) | Максат: Уенчыкларны сыйлар өчен алдагы белгәннәрне искә төшереп тәм том әвәвләү, форма хисен вак моториканы тәрбияләү. | Максат: берничә “бүрәнәләр”дән күпе р ясау, кәеф күтәренкелеге булдыру, эш алымнарын балалардан сорап ныгыту. | Максат: Балалар керпенең үзенчәлекле булуын аңлату. Әвәләү барышында төрле алымнар куллануны ныгыту. |
| Май | Тема: Үрдәк баласы | Тема: Кырыкаяк | Тема: Теләгән кошны әвәләү. | Тема: Ирекле эш |
| | Максат: Үрдәкне күзәтү, төзел ешен , формасын ачыклау, өлешләрнең зурлыгына игътибар итү, чеметү, тартып чыгару алымын өйрәнү | Максат: Әвәләүдә хәрәкәтле уен образын чагылдыра алуны ныгыту. Күзаллауны һәм иҗади эшчәнлекне үстерү. | Максат: Кошларны күзәтү, г әүдә төзелешен , формасын ачыклау, өлешләрне ң зурлыгына игътибар итү, мөстәкыйльлек тәрбияләү, балаларда кызыксыну уяту. | Максат: Балаланың үз теләкләре буенча , өйрәнелгәннәрдән чыгып, әвәләү |

**Танып белү үсеше**

«Танып белү» белем бирү өлкәсе
эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка аш ыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.
Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл) исемнәрен әйтергә өйрәтү. Әйләнә-
тирә (шәһәр яки авылның төп объектлары), янәшәдәге предметлар, аларның билгеләнешләре белән таныштыруны дәвам итү. Кешеләр яши торган йортларның төзелеше, өй кирәк-яраклары турындагы кү-заллауларын үстерү. Балалар бакчасында, өйдә була торган вакыйгаларда (бәй-рәм иртәләрендә, якын кешеләренең һәм яшьтәшләренең ту-ган көннәре h. б. бәйрәмнәр уңаеннан бүләк әзерләүдә ,гаилә бәйрәмнәрендә  кат нашу  h.б. ) актив катнаша сы килү теләгеуяту.Үзүзләрен кунакта, дусларының туган көннәрендә, халык бәй рәмнәрен дә , балалар бакчасында әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрә тү. Урамда, юлларда, җәмәга ть тр анспортында тәртип кагыйдәләре белән таныштыру.
Балаларда ял (бәйрәм) көннәрен кем белән, кайда (цирк-
та, «Кырлай» аттракцион паркында, үзәк мәйданда, шәһәр урамнарында, шәһәрдән читтә) үткәрүләре турында сөйләргә теләк уяту. Вакыйгаларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт чагылы-шын, алган тәэсирләрен өлкәннәр һәм балалар белән бүлешүгә омтылышларын хуплау.
Туган якның кайбер үсемлекләре: агачлар (каен, имән,
чыршы), куаклар (сирень, гөлҗимеш), чәчәк атучы үлән үсемлекләр (тузганак, үги ана яфрагы), бүлмә гөлләре (яран, фикус) белән таныштыру. Бөҗәкләр (күбәләк, камка, энә кара-гы) турындагы күзаллауларын киңәйтү. Үзләре яшәгән җирлектәге йорт һәм кыргый хайваннар,
аларның үзенчәлекләре белән таныштыру эшен дәвам итү. Хайваннар дөньясына, барлык тереклек ияләренә, табигатькә карата кызыксыну уяту. Балаларны тәүлек бүленеше һәм табигатьтәге сезонлы үзгәрешләрне, кешеләрнең ел фасыл-

лары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә белергә өйрәтү. Әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына (салават күпере, агач-
лардагы бәс, беренче чәчәкләр күренү һ. б.га) соклана белү күнекмәләре үстерү.
Табигать белән таныштыру / иҗтимагый тәрбия бирү
Туган якның кайбер үсемлекләре: агачлар, куаклар, чәчәк атучы үсемлекләр, бүлмә гөлләре белән таныштыру. Бөҗәкләр турындагы күзаллауны ныгыту. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).
Үзләре яшәгән җирлектәге йорт һәм кыргый хайваннар, аларның үзенчәлекләре белән таныштыру. Хайваннар дөнҗясына, барлык тереклек ияләренә кызыксыну уяту. Балаларны тәүлек бүленеше сезонлы үзгәрешләрне, кешеләрнең ел фасыллары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә белергә өйрәтү. Әйләнә-тирә табигатҗнең матурлыгына соклана белү күнекмәләре үстерү.
Балалар бакчасында, өйдә булган вакыйгаларда (бәйрәм иртәләрендә, якын кешеләрнең туган көннәрендә, һ.б. бәйрәмнәр уңаеннан бүләк әзерләүдә, гаилә бәйрәмнәрендә катнашу һ.б.) актив катнашасы килү теләге уяту. Төрле һөнәрләр белән танышу. Узенең торган урыны, милләте, шәһәре турында күзаллауларны булдыру. Социаль күренешләр (үзе, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәте турында күзаллаулар) белән таныштыру. Уенчыклар карау. «Тылсымлы» капчык», «Бу өйдә кем (нәрсә) яши?» дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).
Табигать белән таныштыру / иҗтимагый тәрбия бирү буенча перспектив план

| ай | 1нче атна -Табигать белән таныштыру | 2 нче атна- иҗтимагый тәрбия бирү | 3нче атна- Табигать белән таныштыру | 4нче атна- иҗтимагый тәрбия бирү |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | | | Тема: Җиләк-җимешләр | Тема: Юлда |
| | Адаптация | Адаптация | Максат: 1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турын да күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм алар ның билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балалар ның сүз байлыгын үстерү; | Максат: Юл һәм андагы хәрәкәт турында балаларда башлангыч мәгълүмат бирү, юл кыркынычсызлыгы кагыйдәләрен яшь үзенчәлекләренә туры китереп аңлату, транспорт төрлелеге турында әйтеп узу. |
| Октябрь | Тема: Яшелчәләр белән таныштыру | Тема: Камаз машинасы | Тема: Көзге табигать | Тема: Безнең апа |
| | Максат: Балаларның поми дор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; поми дор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре | Максат: Балаларны КамАЗ машинасын һәм аның өлешләрен танырга,исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүзләренә туры китереп, | Максат: 1) балаларның көз (табига тьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади | Максат: Тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш хәрәкә тләрне әйтергә өйрәтү (савыт-саба юа, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (кызыл, йомшак, шома, тәм ле, сусыл, шар формасын дагы помидор; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштыру; | хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру; балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, уңай эмоцияләрен үстерү; | күзаллау ларын формалаштыру; 2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү; | ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмә не җыештыра һ.б.); сүзлекне активлаштыру, яңа сүзләр бе лән баету; уенчыкларны күләм нәре (зур, кечкенә) буенча классификацияләргә өйрәтү; |
| Ноябрь | Тема: Рәсемдәге кошларны карау | Тема: Йомшаккай бездә кунакта | Тема: Күгәрченнәр, чыпчыклар безнең нәни кошчыклар | Тема: Юыну бүлмәсен карау |
| | Бурычлар: балаларда күгәрчен, саескан турында го муми күзаллаулар булдыру, кошларга карата кызыксы ну уяту; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтү чәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү; кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. | Бурычлар:балаларның уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уен-чык исемнәрен һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру; сөй ләм этикетының гади формала рын кул ланырга гадәтләндерү, | Максат: Мәйданчык тагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; гөр-гөр, чырык-чырык, кар-кар аваз ияртемнәрен ачык итеп әйтер гә күнектерү; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырыл дый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баету; | Максат: Балаларны юыну бүл мәсендәге предметлар (сабын, сөлге,кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән танышты ру, функциональ билгеләнеш ләре турындагы күзаллауларын ачыклау; сүзләрне төрле грам матик формаларда куллану ос талыгына ирешү, балалар ның сөйләм активлыгын, үстеру |
| Декабрь | Тема: Гирлянда | Тема: Минем исемем бар | Тема: Җәнлекләр урманда яшиләр | Тема: Чыршы бизибез |
| | Максат: балаларга гирлянда турында башлангыч белем нәр бирү, электр тогы турын дагы күзаллауларын ныгыту; кызыл, яшел, сары төсләрне таный белергә кү нектерү; балаларның игъти барын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү; | Максат: баланы үзенең һәм ип тәшләренең исемен әйтергә өйрә тү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү; тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, фразаларны кабатларга күнектерү; балаларның хәтерен, игътибарын үстерү; балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә кара та ягымлылык тәрбияләү. | Бурычлар: җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ны-гыту, җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү; балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү; җәнлекләр белән кызыксындыру. | Бурычлар: балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллаула рын баетуны дәвам итү; балалар ның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүзлеген активлаш тыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтү чәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү; чыршы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү |
| Январь | Каникуллар | Тема: Яраткан уен бүлмәбез<br><br>Максат: балаларны балалар бакча сы шартларына ияләндерүне дә вам итү, төркемдәге уен бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, «һәр әйбернең үз уры ны» дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту; сүзләрне һәм кыс ка фра заларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү; җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягым-лылык тәрбияләү. | Тема: Йорт хайваннары<br><br>Максат: балаларның йорт хайван нары (сыер, ат, песи, эт) турын дагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайван нарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;) сүзлекне бае ту, тәрбиячененң сорауларына җа вап бирү, мөстәкыйльлек һәм ак тивлык күрсәтү теләген үстерү; йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. | Тема: «Безнең урам»<br><br>Бурычлар: балаларны урам, андагы объектлар, күренешләр белән таныш-тыру, аларга карата кызыксыну тудыру; балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүз байлыгын үстерү; урамга соклану хисе тәрбияләү. |
| Февраль | Тема: Ап-ак кар ява<br><br>Максат: Карның үзлекләре белән танышу.(кар бөртекләр дән тора, алар күбәя, кар өеме хасил итә), карның тиз эрүчәнлеген тәҗрибә аркылы төшендерү, гигиеник таләпләрне үтәү. | Тема: Безнең әтиләр<br><br>Максат: Балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрне карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү; | Тема: Боз һәм су<br><br>Максат: Балаларны боз белән таныштыру, аның ничек барлыкка килүе турында сөйләү, участокта тәҗрибә үткәрү, җылы тирәлектә бозның эреп суга әйләнүе турында аңлату, | Тема: Бу — мин<br><br>Бурычлар: организм һәм аның өлешләре турында балаларда күз аллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрә тү, гәүдә өлешләре турын да бе лемнәрен ачыклау һәм ныгыту; гәүдә өлешләренең атамалары хи сабына бала ларның сүзлеген ак тивлаш тыру; үзеңне, гәүдә өлешләрең не ярату, |
| Март | Тема: Рәсемдәге кошларны карау<br><br>Максат: балаларда күгәрчен, саескан | Тема: . Безнең Әниләр (сюжетлы рәсемнәр карау)<br><br>Бурычлар: балаларны әниләр һөнәренә | Тема: Яз, яз килә...<br><br>Бурычлар: балаларга язгы күренешләр (кар | Тема: Җыештыручы<br><br>Максат: Балаларны җыештыручы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | турында гомуми күзаллаулар булдыру, кош ларга карата кызыксыну уя ту; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтү чәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү;кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. | кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш-хәрәкәтне белдерә тор-ган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үсте рү; балаларның кабул итү сәлә тен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталы гын, игътибарын, әниләр карата хөрмәт тәрбияләү. | эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) турында башлангыч белемнәр бирү, сүз бай-лыгын киңәйтү һәм активлаштыру; балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү; табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. | хезмәте белән таныштыру , пешекчеләр бүлмәсенә экскурсия, киемнәр енә нинди эш кораллары белән кулларына игътибар иттерү. |
| Апрель | Тема: Сыерчыклар, карлы гачлар килде (рәсемнәр карау) | Тема: Матрёшкалар | Тема: Песиле тал бөреләрен карау | Тема: Бәйрәмнәр |
| | Максат: балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга һәм исемнәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру, сүзлеккә сыерчык, сыерчык оясы, карлыгачсүзләрен кертү; игътибарны, күзәтү чәнлекне, тәрбияче белән ара лашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; | Максат:<br>Максат: уенчыкның исемен (матрёшка) дөрес әйтергә, төсендә һәм зурлыгында булган әерманы күрә белергә кү нек терү; зур, кечкенә, сарафан, яулык сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру; балаларның игъ тибарын, күзәтүчәнлеген, сорау ларга җавап бирү осталыгын үс терү; балаларда халык уенчык ларына кызыксыну тәр бияләү. | Бурычлар:)<br>балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр ту рында белемнәр формалаш тыру ны дәвам итү; сүз байлыгын ки ңәйтү һәм песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш ислесүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру; балалар ның кабул итү сәләтен, игъти барын, , хәтерен, үстерү; | Максат: Балаларны татар, урыс, башка милләт халкының йола бәйрәмнәре, календарь бәйрәмнәр белән таныштыру, халкыбызның узенчәлекле бәйрәмнәре белән горурлану хисләре тәрбияләү, бәйрәмнәрдә бүлмәләр, зал, урамнарның бизәлеше турында сөйләү |
| Май | Тема: Ком һәм аның үзлекләре | Тема: «Безнең Алсу» сериясеннән рәсем карау | Тема: Тузганак чәчәген карау | Тема: Йорт хайваннары |
| | Максат: балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү; коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү сүзләре | Максат рәсемдәге предметларны таный һәм исемен әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәт- | Максат: балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү; тузга-нак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; | Максат: балаларны ң йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннар-ның исемнәрен, хәрәкәтләрен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хисабына балалар ның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү; ком белән уйнарга кызыксындыру. | мәләрен ишетә һәм үти белүләренә ирешү; рәсемне кызыксынып карау теләге тәрбияләү. | сүз байлыгын үстерү; тузганак, чәчәк, сабаксүзләрен сөйләмдә активлаштыру; балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзә түчәнлеген үстерү | әйтергә күнектерү; сүзлекне баету, тәрбиячeнең сорауларына җавап бирү, мөстә-кыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү; |

**Сөйләм үсеше**

«Сөйләм үстерү» әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чараларын үзләштерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели. Баланы туган телендә төрле темаларга сөйләшергә, аралашырга өйрәтү; күргәннәре турында күзаллап сөйләргә генә түгел, тормышында булган вакыйгалар, башкарган эш-гамәлләре, үзен кызыксындырган күренеш һәм предметлар, туган як табигате объектлары турында да сөйләргә күнектерү.Сорауларга җавап бирергә өйрәтү. Үз фикерләрен әйтү, үтенеч һәм тәкъдимнәр белән өлкәннәргә мөрәҗәгать итү омтылышларын хуплау. Таныш булган татар (рус) халык әкиятләреннән өзекләр, шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү. Балаларның уен барышында үзара мөнәсәбәтләрен (уендагы үзләренең эш-гамәлләре турында сөйлиләр, уенчыклар, аларны алмаштыручы предметларны сүзләр белән атыйлар) җайга салырга булышу. Балаларның сөйләмен барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү өчен кирәкле сүзләр белән баету.

«Матур әдәбият уку» балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатл арын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларынбилгели. Көчле хис-кичерешләр чыганагы булган китапка һәм өлкәннәр белән әдәпле аралашуга кызыксыну формалаштыру. Яшьтәшләре белән бергәләп тәрбиячeнең сәнгатьле уку яки сөйләмен тыңлау күнекмәләре булдыру. Татар халык әкиятләрендә, язучы һәм шагыйрьләрнең әдәби әсәрләрендә вакыйгалар барышын күрсәтмәлелек (уенчыклар, рәсемнәр, хәрәкәтләр) ярдәмендә күзәтергә, аларның эчтәлеген сүзләр, хәрәкәтләр, ишарәләр белән белдерергә өйрәтү. Уен гамәлләрендә катнашасы килү теләге булдыру, кыен булмаган сорауларга җавап бирергә, кара-каршы сөйләшүләр алып барырга күнектерү. Әдәби әсәрләргә карата хисси кичерешләр булдыру, әдәби сүзгә кызыксыну уяту. Китаптагы иллюстрацияләрне караганда, әдәби әсәр геройларын һәм аларның гамәлләрен таныргa булышу. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре (юаткычлар, әйтемнәр, бармак уеннары)
белән таныштыру. Кече фольклор формаларын көндәлек тормышта куллануны хуплау.

Матур әдәбият уку

«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру
максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Көчле хис-кичерешләр чыганагы булган китапка һәм өлкәннәр белән әдәпле аралашуга кызыксыну формалаштыру.

Яшьтәшләре белән бергәләп тәрбиячeнең сәнгатьле уку яки сөйләмен тыңлау күнекмәләре булдыру.

Уен гамәлләрендә катнашасы килү теләге булдыру, кыен булмаган сорауларга җавап бирергә, персонаһларга үз мөнәсәбәтен белдерергә, кара-каршы сөйләшүләр алып барырга күнектерү.
Әдәби әсәрләргә карата хисси кичерешләр булдыру, әдәби сүзгә кызыксыну уяту.

«Үчтеки, үчтеки» такмагын уку; Ә. Бикчәнтәеваның «Туп-туп- тубы быз» шигырен уку; С. Сөләймәнованың «Ике» шигырен уку; Йорт хайваннарын чакыру эн дәшләрен уку; Д. Гарифуллинның «Йә, алар кемнәр икән?» шигырен уку;
Б. Рәхмәтнең «Су» шигырен уку; Г. Тукайның «Гали белән кәҗә» шигырен уку; З. Туфайлованың «Ул зу-у-у-р үскән» шигырен уку «Песи-нечкәбил» бишек җырын җырлау; М. Җәлилнең

«Маэмай» шигырен уку ;М. Җәлилнең “Әтәч» шигырен уку; Җ. Тәрҗе мановның «Маэмай» шигырен уку; Ә. Бикчәнтәенның «Беренче адым» шигырен  уку «Карга әйтә» эндәшен уку; Ә. Ерикәйнең  «Беренче кар» шигырен уку ;Җ. Тәрҗемановның «Йокы бабай» әкиятен сөйләү; С. Летованың  «Кар бабай» хикәясен уку; Ш. Маннурның «Яратам» шигырен уку; “Кәккүк-чыпчык» уены;  Таһированың «Йокла, курчак» шигырен уку; Э. Шәрифуллинаның «Иң матур әни» шигырен уку; Ә. Каринның «Тавык» шигырен уку; «Йомры икмәк» рус халык  әкиятен уку; «Теремкәй» рус халык әкиятен уку; Ш. Галиевнең «Яз» шигырен уку; «Тор-тор, тургай»  такмагын уку; «Тук, тук, тукран» эндәшен уку; «Кояш, чык, чык» эндәшен уку;  Р.Батулланың «Нурбәк» әкиятен уку; Д. Ушинскийның «Казлар» хикәясен уку; Ә.Каринның «Чебиләр» шигырен уку; С. Сөләйманова ның Кызыл әтәч» шигырен уку; Д. Гарифуллин ның «Мыраубикә» шигырен уку.

**Матур әдәбият укубуенча перспектив план**

| Ай | 1нче атна | 2 нче атна | 3нче атна | 4нче атна |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | | | Тема: «Үчтеки, үчтеки» такмагын уку | Тема: З. Туфайлованың “Шофер булам” шигырен уку |
| | Адаптация | Адаптация | Максат:.  балаларны фольклор әсәрләре белән кызыксындыру, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү; | Максат: шофер хезмәтенә карата кызыксыну уяту, юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәклеген төшендерү |
| Октябрь | Тема: Ә. Бикчәнтәеваның «Туп-туп- тубыбыз» шигырен уку | Тема. Хайваннарны чакыру Эндәшен уку | Тема: С. Сөләй мановаң «Ике» шигырен уку | Тема: . Җ. Тәрҗемановның «Йокы бабай» |
| | Максат: балаларга шигырь-нең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, таныш предметларны таный һәм атый белергә, шигырьнең авыр әйтелешле аерым сүзләрен дөрес әйтергә өйрәтү | Максат: эндәшнең эчтәлеген аңлату, текстның эчтәлегеннән чыгып,аваз ияртемнәрен, ымлык ларны дөрес әйтүләренә, тәрбия че сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү; балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоция ләрен үстерү; | Максат: шигъри әсәр белән кызык-сындыру, аның эчтәлеген аңларга өйрәтү, баланың үзе турында күзаллавын формалаштыруны дәвам итү; сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру | Максат: әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; балаларның игътибарын үстерү; сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы уяту. |
| Ноябрь | Тема: Д.Гарифуллинның «Йә, алар кемнәр икән?» шигырен уку | Тема: . К. Ушинскийның «Казлар» Хикәясен уку | Тема: Б. Рәх мәтнең «Су» шигырен уку | Тема. Ә. Ерикәйнең «Беренче кар» Шигырен уку |
| | Максат: шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дә вам итү; бак-бак, мә-мә, кар-кар | Бурычлар: казларны һәм үрдәк ләрне аера белергә өйрәтү, хикә яне күрсәтмәлелек | Максат: текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрә тү, [йу] аваз кушылмасын | Максат шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, әсәр аша табигать |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аваз ияртемнәрен кабатлау; балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итү, сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру | кулланмыйча, аңлап кабул итүләренә ирешү; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбия-ченең күрсәтмәләрен үти алу осталыгын үстерү; | ачык итеп әйтергә күнектерү; сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру; балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү; | дөньясына җәлеп итү, кышкы табигать турында мәгълүматбирү; йомшак, ап-ак сыйфатлары хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру; |
| Декабрь | Тема: З. Туфайлованың «Ул зу-у-у-р үскән» шигырен уку | Тема: Ә. Бикчәнтәеваның «Беренче адым» Шигырен уку | Тема: «Песи нечкәбил» бишек җырын җырлау | Тема: Ш. Маннуровның “Яратам” шигырен яттан өйрәнү |
| | Максат: утырткан, сипкән, үскән кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, диалогик сөйләм күнекмәсе формалаштыру | Максат. балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, авыр әйтелешле кайбер сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү; сорауларга җавап бирү күнекмәсен үстерү; күмәк эшчәнлек күнекмәсе тәрбияләү. | Максат: шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бишек җыры текстына туры китереп, хәрәкәтләр өйрәтү;балаларның игътибарын үстерү; фольклор әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү | Максат: Сүзлекне баету һәм активлаштыру, гаилә сүзен сөйләмдә куланырга өйрәтү |
| Гыйнвар | Кышкы каникуллар | Тема: С.Летованың «Кар бабай» Хикәясен уку | Тема: М. Җәлилнең «Әтәч» шигырен уку | Тема: М. Җәлилнең «Маэмай» шигырен уку |
| | | Максат: күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне күрсәтмә лелек кулланмыйча тыңлау һәм кабул итү, сораулар га аңлаешлы итеп җавап бирү осталыгын үстерүне дәвам итү, балаларның әңгәмә вакытында җиңел һәм иркен аралашуларына ирешү, сүз байлыгын арттыру; | Максат: балаларның игътибарын, кабул итү һәм тыңлау сәләтен үстерү; йорт кошларына карата шәф катьлелек тәрбияләү; кабул итү сәләтен, игътибарны, тыңлау осталыгын үстерү; йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. | Максат: шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бармак театры элементларын өйрәтүне дәвам итү, сүз байлыгын арт ты ру; кабул итү, хәтердә калдыру сәләтен үстерү; йорт хайванна рына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| Февраль | Тема: Җ. Тәрҗе мановның «Маэмай» шигырен уку | Тема: . «Кәккүк — Чыпчык» уены | Тема: «Карга әйтә» эндәшен уку | Тема: Г.Таһированың «Йокла, курчак» Шигырен уку |
| | Максат: шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, аерым сүзләрне | Максат: ачык итеп әйтергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру; | Максат: шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, | Максат: шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | истә калдырырга өйрәтү; эткә карата миһербанлылык тәрбияләү | балаларның эмоциональлеген үстерү; фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. | балалар ның кошлар турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту, аларның тышкы кыяфәтенә игътибар итү, сүз байлыгын арттыру; балалар ның игътибарын үстерү; кошлар белән кызыксыну теләге уяту | ирешү, балаларның игътибарын үстерү; курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләү. Җиһазлар: коляскада йокларга яткырылган курчак, һәр балага бирәр курчак. |
| Март | Тема: Э. Шәрифуллинаның «Иң матур әни» | Тема: Р. Батулланың «Нурбәк» экиятен уку | Тема. «Теремкәй» Рус халык экиятен уку | Тема: Тема. «Тор-тор, тургай» такмагын уку |
| | Максат: Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйлә мен активлаштыру | Максат: әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү; уенчыкларда экият персонажла рын танырга һәм атарга өйрәтү; балаларның игътибарын үстерү; экият геройлары белән кызыксы ну тәрбияләү. | Бурычлар: балаларны яңа әсәр белән таныштыру, экиятне аңлап кабул итүләренә ирешү; балалар ның игътибарын үстерү; халык иҗаты белән кызыксыну тәрбияләү. | Максат: такмакның эчтәлеге белән таныштыру,әйтер гә кү нектерү, аваз ияртемнәре хиса бына балның сүз байлыгын арт тыру; кабул итү сәләтен, игъти барны, хәтерне үстерү; фоль клор әсәрләре белән кызык сыну тәрбияләүне дәвам итү. |
| Апрель | Тема: . Ә.Каринның «Тавык» шигырен уку | Тема: «Йомры икмәк» рус халык экиятен уку | Тема: Г. Тукайның «Гали белән кәҗә» шигырен уку | Тема: «Тук-тук, тукран...» эндәшен уку |
| | Бурычлар: шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү, кайбер фразаларны ка батлатып, балаларның сөйлә мен активлаштыру; балалар ның игътибарын, кабул итү сәләтен, сораулар га җавап бирү осталыгын үстерү; әбиләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. | Максат: балаларны «Йомры Икмәк» экияте белән таныш тыру, экиятэчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; кабул итү сәләтен, игътибарны үстерү; экиятләр белән кызыксындыру. . | Максат: шигъри әсәрне аңлап ка бул итүләренә ирешү, балаларда «Мин — дөньяның бер кешесе» дигән күзаллау булдыру; кәҗә, чирәм, сакал сүзләре хисабына сүзлек байлыгын киңәйтү, хәрәкәтләр өйрәтүне дәвам итү; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, уңай эмоцияләрен үстерү; | Максат: шигъри текстны тыңлау осталыгы формала штыру, кошлар белән таныштыруны дәвам итү, балаларның игътибарын үстерү; кошларга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| Май | Тема: Ш. Галиевнең «Яз» ши гы рен уку | Тема: «Кояш, чык, чык!» эндәшен уку | Тема: Ә.Каринның «Чебиләр» шигырен | Тема: С. Сөләймānованың «Кызыл |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әтәч»шигырен уку |
| | Максат:балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү; язгы табигать күренешләре белән соклану хисе тәрбияләү | Максат: балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетны истә калдырырга ярдәм итү; балалар ның тыңлый белү осталыгын, уңай эмоцияләрен үсте рү; күмәк эшчәнлек белән кызыксындыру. | Максат: күрсәтмәлелек кулланмыйча, шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, [ч] авазын дөрес әйтергә кү нектерү; балаларның уңай эмоцияләрен үстерү; йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | Максат:шигъри әсәрне тыңлар га өйрәтү, гади сорауларга җа вап бирү теләге уяту, аваз ияр темнәрен өйрәтүне дәвам итү; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәр бияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү; йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |

**Сөйләм үстерү**
Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып үткәрелә. Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомум кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.
Сөйләм үстерү буенча перспектив план

| ай | 1нче атна | 2 нче атна | 3нче атна | 4нче атна |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | | | Тема: Юлда булсаң – бул өлгер. | Тема: Кем нәрсә эшли? |
| | Адаптация | Адаптация | Максат:. Балаларны юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү, Урамның тротуар һәм машиналар йөри торган өлешен аерырга өйрәтү; түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү. | Максат балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын атарга, рәсемдә сурәтләнгән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү; игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү; уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| Октябрь | Тема: Уенчыклар бездә кунакта | Тема: Пирамидалар | Тема: . Яшелчәләр | Тема: «Жил исә» уен күнегүе. «Кем нәрсә ашый?» дидактик күнегүе |
| | Максат: төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгы формалаштыру ; балаларның предметны исеме, төсе, зурлыгы буенча табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү; . | Максат: балаларны предметлар ның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү; төсне (кызыл, яшел, сары, зәңгәр), зурлыкны (зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк, иң зурысы, иң кечкенәсе) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүз байлыгын арттыру; аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерү; игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү; | Максат: яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (бәрәңге, помидор, суган, кишер) һәм аларның үзлек ләрен белдерә торган сүзләр хиса бына балаларның сүзлеген баету, яшелчәләрне танырга өйрә тү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; балаларның сенсор тою сәләтен үстерү; яшелчәләр, аларның файдасы турында мәгълүмат бирү. | Максат: балаларның төсләр турындагы күзаллавын ны гы ту, җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачык лау; ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый фигыльләрен сөйләмдә активлаштыру; авыз аша һава ны әкрен, салмак кына чыга рырга өйрәтү; игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү; җәнлек ләргә, кошларга карата кызык сыну тәрбияләү. |
| Ноябрь | Тема: Урманда | Тема: Алсу бүлмәсе | Тема: «Бу өйдә кем яши?» Дидактик уены | Тема: Әминәнең туган көненә килегез |
| | Максат: балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау, | Максат: балаларны өй җиһазларын таный һәм атый белергә өйрәтү; өстәл, урындык, карават, шкаф, көзге кебек исем нәр хисабына | Максат: төркемгә йөрүче балаларның исемнәрен истә калды рырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда кул | Максат: [к] һәм [к] авазларының сүзләрдә һәм сөйләмдә дөрес әйтелешен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | исем һәм сыйфатлар ны кулланырга өйрәтү: йом шак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре; кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштыру (төлке бара, куян сикерә, аю алпан-тилпән йөри һ.б.); ишетү игътибарын, координацияне, ритм хисен үстерү; кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләү. | сүзлекне активлаш тыру, сөйләмнең грамматик төзе лешен камилләштерү; балалар ның эмоциональлеген, кызыксы нуларын үстерү; эшчәнлектә бергәләп катнашу теләге тәрбияләү. | ла на белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү; игътибарны, кабул итү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү; гаилә турындагы күзаллауны киңәйтү, уенчыкны карауны балаларны җәлеп итү. | ныгыту, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтү, савыт-саба ларны белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрне (савыт-саба) аңлый һәм куллана белүләренә ирешү, җөмләләр белән җавап бирергә күнекте рүне дәвам итү; инициатива лы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерү, башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудыру; үзара аралашуга омтылыш тәрбияләү. |
| Декабрь | Тема: Минем гаиләм | Тема: Купшы чыршы | Тема: Куян чыршы янында | Тема: Песи белән кәҗә чыршы янында |
| | Максат: сөйлә мдә ягымлы сүзләрне (эти — этием, әни — әнием, әби —әбием, се цел — сең лем) кулланырга өйрәтү; [ә] авазының әйтелешен ныгыту, аны ачык, тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүләренә ирешү, | Максат: сузык һәм тартык авазларны, аваз ияртемнәрен ачык әйтергә, төбендә сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү; сыйфатларны дөрес кулланырга күнектерү; сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү; табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. | Максат: сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстендә) кулланырга, кайда? кая? сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү; тавыш көчен дөрес куллану осталыгы формалаштыру; игътибарны үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү; нәфис сүз белән кызыксыну тәрбияләү. | Максат: балаларн ы тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, сөйләмдә фигыльләр һәм сыйфатлар кул ла нуны активлаштыру; [ж] авазын иҗекләрдә, сүзләрдә һәм җөмләләрдә дөрес һәм ачык әйтүләренә ирешү; аваз ияр тем нәрен кабатлаганда, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү; игъ тибарны, хәтерне үстерү; зурлар һәм үз яшьтәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү; гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү. | | | тавыш көчен җайлый белергә күнектерү; игътибарны, кабул итү сәләтен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү; хайваннар га карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| Январь | Кышкы каникуллар | Тема: «Тылсымлы» таякчык | Тема: Кошлар | Тема: . Юлны чистартабыз |
| | | Максат: балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү; төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сыйфатларны активлаштыру; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү; эшчәнлектә бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. Авазларны дөрес артикуляция белән әйтергә өйрәтү, uгътибарлылык тәрбияләү, чи ста сөйләм күнекмәләрен үстерү, актив сүзлек булдыру. | Максат: балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтер гә, алардан фигыльләр (гөр — гөрли, чырык — чыркылдый, кар — каркылдый) ясарга өйрәтү; гомумиләштерүче сүзләрне (та вык, әтәч, каз — йорт кошлары) кулланырга күнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен, хәрәкәтләрне белдерүче сүзләр хисабына сүз байлыгын активлаштыру, балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итү; балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмен үстерү; кошларга карата кызыксыну, кайгыртучанлык тәрбияләү. | Максат: балаларның кыш һәм кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру, кө рәк белән эшләргә өйрәтү, ише галды җыештыручы хезмәте белән таныштыру; балаларның сүз байлыгын арттыру һәм ак тивлаштыру, аерым сүзтезмә ләрне (зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар, күп кар, әз кар) дөрес әйтергә өйрәтү; хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәт ләрен имитаци яләү осталыгын үстерү; зурлар га ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләү. |
| вр ал | Тема: Йөк машинасы | Тема: Машина һәм самолёт | Тема: «Шундый ук предметны тап» дидактик | Тема: Алсу бездә кунакта |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | уены | |
| | Максат: машина, аның өлешләре турында белемнәрен арттыру, ком һәм аның үзлекләре белән таныштыру, машинаның төрен, өлешләрен, комның үзлекләрен белдерә торган исемнәр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштыру; [в], [п] авазларын дөрес әйтүдә күнектерү; кызыксынучанлыкны, кабул итү сәләтен үстерү; тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү. | Максат: балаларны уенчыкларның өлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; [у] сузык авазын әйтүдә күнектерү, сүзлекне активлаштыру; уенчыклар белән таныштыруны дәвам итү; балаларның нинди? кайда? нәрсә ташый? сорауларына төзек гади җөмләләр белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү; шофёр, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. | Максат: үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белд ерергә өйрәтү, гомуми ләш терү күнекмәсе булдыру, предметларны чынбарлыкта һәм рәсемдә танырга өйрәтү, предметларның билгелә нешен ачыклау, сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру; тәрби яче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгын, игъти барны, сенсор тою сәләтен үстерү; гигиена күнекмәләре тәрбияләү. балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым үзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, сүзлекне баету; | Максат::балаларга табиб, полиция хезмәткәре һөнәрләре турында мәгълүмат бирү; грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү; игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабул итү сәләтен үстерү; һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү. Тәрбияче биргән сорауларга җавап бирергә гадәтләндерү,уенчыкның нинди материалдан ясалуын әйтеп бирергә өйрәтү, пластмасса, агач, тукымадан ясалган уенчыклар турында сөйләү |
| | Тема: Безнең әниләр (сюжетлы рәсемнәр карау) | Тема: Мәрьямне табыйк | Тема: Бармак уены белән таныштыру. | Тема: «Паровоз» дидактик күнегүе |
| Март | Максат: балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сю-жетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр | Максат:: балаларны кайда? кая? сорауларына җавап бирергә; сөйләмдә өстенә, артына, астына сүзләрен кулланырга өйрәтү; балаларның игътибарын, хәтерен үстерү; уен белән кызыксыну тәрбияләү. Балаларның сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен гомумиләштерү, сорауларга | Максат: халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны куллануда күнектерү, йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту; мөгри, кычкыра, мияулый, өрә фигыльләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру; | Максат: төсләрне белдерә торган сыйфатлар хисабына балаларның сөйләмен баету (кызыл, яшел, сары), [ү] авазының дөрес әйтелешенә ирешү; балаларның |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү | тулы һәм дөрес җавап бирергә өйрәтү, монологик сөйләм күнекмәләре бирү. | [м], [у] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү; хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнекмәләрен үстерү; халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. | игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү; эшчәнлеккә карата кызыксыну, күмәк эшчәнлек белән шөгеллэнугэ кызыксыну уяту. |
| Апрель | Тема: Бүлмә гөлләре | Тема: «Чуар тавык» әкиятен уку | Тема: Язгы урманда | Тема: Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие, Сез кайда? |
| | Максат: балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету; гөлләр белән кызыксынуларын үстерү; гөлләрне караганда, өлкәннәргә ярдәм итү теләге тәрбияләү. | Максат: балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру; чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету; тәрбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү; әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү. | Максат: кайда? нинди? сорауларына җавап бирергә өйрәтү; өстә,агач төбендә сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; аваз иярсемнәрен дөрес әйтүдә күнектерү; [ш] авазының дөрес әйтелешен ныгыту, ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турында белемнәрен формалаштыруны дәвам итү; балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү; табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. | Максат: балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие сүзләре хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру; игътибарны, хәтерне үстерү; башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| Май | Тема: . Балалар бакчасы ишегалдында | Тема: Кызыксынучан тел | Тема: Зоопарк | Тема: Рәхмәт, җәй! |
| | Максат: исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүз байлыгын үстерү, фигыль | Максат: балаларны [т], [д], [к], [к] авазлары кергән аваз иярсемнәрен әйтергә өйрәтү; аваз иярсемнәрен калын һәм нечкә тавыш белән әйтүдә күнектерү; [т], [д], [к], [к] авазларының сүзләрдә, | Максат: җылы якта яшәүче кайбер хайваннар белән таныштыру; сөйләмдә исемнәрне берлек һәм күплек санда дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү; сөйләшеп, | Максат: балаларны яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне тәме буенча аерырга өйрәтүне дәвам итү; яшелчәләр, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ләр не һәм сыйфатларны исем нәр белән яраклаштыруда күнек тергү; балаларны бакча ишег алдында үсә торган үсем лек ләр исеме белән таныш тыру ны дәвам итү, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турын да белемнәрен киңәйтү; төсләр не, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентлары н үстерү; табигать объектларына карата кызыксыну, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү. | фразаларда дөрес әйтелешенә ирешү; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын үстерү; игътибарлылык тәрбияләү. | әңгәмә корырга өйрәтү; кабул итү сәләтен, игътибарны үстерү; җылы як хайваннарына карата сакчыл караш тәрбияләү. | җиләк-җимешләр, агачлар турындагы белемнәрен киңәйтү; кабул итү сәләтен, игътибарны үстерү; игътибар белән тыңларга өйрәтү, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |

**Физик үсеш**
«Физик культура» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели. Хәрәкәтле уеннарда балаларның хәрәкәт активлыгын формалаштыру. Шуышу, үрмәләү күнекмәләрен үстерүче уеннарны, тупны ыргыту һәм тотып алу уеннарын хуплау. Акрынлап катлаулырак кагыйдәле һәм хәрәкәтләр алмашынулы уеннар уйнарга өйрәтү.
«Сәламәтлек» эчтәлеге балаларның сәламәтлекләрен саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларынбилгели. Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту; учреждение төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш торышы үзенчәлекләрен, шулай ук төбәкнең климатик шартларын һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын системалы чыныктыруга, хәрәкәтләрнең төп төрләре форма-лашуга һәм камилләшүгә шартлар тудыру. Культура-гигиена процедураларының төп алгоритмнары белән таныштыру. Балаларны гигиена процедураларын аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә башкарырга гадәтләндерү. Сабынны дөрес куллану, кулларны, битне, колакларны чиста юу; юынгач коры итеп сөртенү, сөлгене урынына элү, тарак һәм кулъяулык куллану күнекмәләрен формалаштыру. Өстәл янында үз-

үзеңне дөрес тотуның иң гади күнекмәләрен формалаштыру: аш һәм чәй кашыкларын, чәнечке, салфетканы дөрес куллану. Ипине вакламаска, азыкны түкми-чәчми ашарга, ризык-ны авызны ябып чәйнәргә, ашап туйгач рәхмәт белдерергә күнектерү. Милли ризыклар белән таныштыру. Файдалы һәм зарарлы азык-төлек турында күзаллау булдыру. Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру. Үз сәламәтлегеңә һәм якын кешеләреңнең сәламәтлегенә сакчыл караш тәрбияләү. Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм пөхтәлек булдыруга ихтыяж формалаштыру.
«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели. Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру
